Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Иске Котыш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлегенең Красная Поляна торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

22 октябрь 2024 ел . № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 22 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Красная Поляна авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәйге һәм кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Красная Поляна торак пунктында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу), халыкның массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм Красная Поляна торак пунктында җәмәгать урыннарын төзекләндерүне оештыру).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының **11** катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **9** кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:
**«РИЗА»** позициясе өчен гражданнар җыенында **9** кеше тавыш бирде;
**«КАРШЫ»** позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.
Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге составына керүче Красная Поляна торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Красная Поляна торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәйге һәм кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү чыгымнары, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Красная Поляна торак пунктында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу), халыкның массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм Красная Поляна торак пунктында җәмәгать урыннарын төзекләндерүне оештыру) кабул ителгән дип танырга.

3. Мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә: Красная Поляна авылы, Лесная ур., 24/1 нче йорт, Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Иске Котыш авыл җирлеге башлыгы А.К.Митякин